РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422057, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТИМЕРШЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422057, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы,
19а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail:Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.03.2019 № 11

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Тимершык
авыл җирлеге Советы тарафыннан
2014 нче елның 14 нче ноябрендә
кабул ителгән 28 нче номерлы
«Татарстан РеспубликасыСаба
районы Тимершык авыл җирлегендә
физик затларның мөлкәт салымы
турында»карарына үзгәрешләр
кертү турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 32 нче бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 64 нче маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Саба районы Тимершык авыл җирлеге Советы **к а р а р** и т т е:

1.2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 28 нче номерлы Тимершык авыл җирлеге Советы карары белән расланган “Тимершык авыл җирлегендә физик затларның мөлкәт салымы турында” карарына (Тимершык авыл җирлеге Советының 2015 елның 07 нче августында кабул ителгән № 24, 2015 елның 08 октябрендә кабул ителгән №10, 2018 елның 03 августында кабул ителгән №16, 2018 елның 21 ноябренда кабул ителгән №32 карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ 3. Түбәндәге ташламаларне кертергә:

3.1. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә бирелә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламалар суммасы өлешләп милектәге һәр кеше өчен аның бу фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

3.2. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар-физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.

Салым ташламасы салым салу объектларының чикләнмәгән санына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының теләсә нинди төренә карата бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар бирергә хокуклы.».

2. Әлеге карарның 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә йогынтысын җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Тимершык авыл
җирлеге башлыгы Хаҗиев А.Х. Хаҗиев